Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең
Яңа Шөгер торак пунктында гражданнар җыены карары

2024 елның 23 ноябре №3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең
Яңа Шөгер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 18 яшькә җиткәннәрнең гомуми санының 30% тан артмаска тиешле кешеләр, 1 төркем инвалидлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомумкуллану әһәмиятендәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Шөгер авылының Гагарин урамындагы юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, шартнамә буенча түләү); Яңа Шөгер авылындагы юлларны кардан чистарту).
2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Шөгер авылында юл кырыеннан чүп үләнен чабу (тракторчыга килешү буенча түләү); урам яктырткычлары сатып алу).

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 171 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 93 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 93

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. « Сез Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 18 яшькә җиткәннәрнең гомуми саныннан 30% тан артмаска тиешле кешеләр, 1 төркем инвалидлардан, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомумкуллану әһәмиятендәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Шөгер авылының Гагарин урамындагы юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, шартнамә буенча түләү); Яңа Шөгер авылындагы юлларны кардан чистарту).

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Шөгер авылында юл кырыеннан чүп үләнен чабу (тракторчыга килешү буенча түләү); урам яктырткычлары сатып алу).

чаптыру, авария хәлендәге иске агачлар һәм куакларны кисү ( килешү буенча түләү))

соравы буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет ур., 1 йорт, Совет ур., 3 йорт буенча балалар бакчасы бинасы, М. Җәлил урамы 33нче йорт янында, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Иске Шөгер авыл җирлеге башлыгы Л.М.Шиһапова